

***Рөстәм МАЛИКОВ,***

*җырчы, музыкант, Татарстанның халык, Башкортстанның атказанган артисты*

Мин, Әлфия апа белән Илһам абый җырларын тыңлап үстем. Аларның җаннарны әсир итәр моңнары минем өчен ниндидер бер могҗиза иде. Тора-бара үзем дә җыр сәнгатенә кереп киттем. Уфа филармониясеннән кайткач, Казан филармониясендә үз бригадамны төзергә рөхсәт алдым. Әмма 1990 елгы, үзгәртеп кору чорында халык концертларга йөрми башлагач, бригадамны таркатырга мәҗбүр булдым, шуннан соң мине танылган җырчы Әлфия Авзалова үз бригадасына алды. Мин җыр сайлауга бик таләпчән, кайбер җырчылар репертуарындагы җырларны еш кына ошатмыйм, күңел кабул итми. Әлфия Авзалова төркеменә килгәч, миңа ошамый торган җырларны Әлфия апа башкаруында тыңлап шаккаттым. Шул чакта үзем өчен, хикмәт җырда түгел, ә башкаручыда икән, дигән ачыш ясадым. Миңа Әлфия апа көчле рухлы булуы, тормышны яратуы белән ошый иде. Әйтүемчә, 1990 еллар, кибеттә бернәрсә юк. Ә без концерт куеп кайтканда гаиләләребезне туендырырга капчык-капчык азык-төлек: ит, ярма, шикәр комы һ.б алып кайтабыз. Бервакыт мин кызык өчен, юри генә, Зәйтүнә Яруллина автобустан төшкәндә, ул алып кайткан ризыкларның исәбен чутладым: бер кешегә – 16 тартма ризык! Авыл җирлекләрендә концерт куеп йөрүләр – үзе бер онытылмас хатирә. Әлфия апаны хөрмәтләү йөзеннән, күп колхоз рәисләре безнең өчен махсус мал чалдыра. Итне чабып, өлешләргә бүлеп куялар да, берәү артка борылып, бу кисәкнең кемгә икәнлеген атый. Менә шундый гадел, кешелекле, киң күңелле иде ул безнең Әлфия апабыз. Шуңа күрәдер, Әлфия апа бригадасыннан бер генә артистның да китәсе килмәде. Безнең төркемдә һәрвакыт дуслык, татулык, бердәмлек хөкем сөрде.

Истә калырлык кызык вакыйгалар бик күп булды инде. Бервакыт Әлмәттән кайтыр юлга кузгалдык, без төялгән автобусны ниндидер бер кәттә машина куып тотты да, ике ир-ат исерткеч эчемлекләр тутырылган ике тартманы кертеп, «Сезгә күчтәнәч», – дип, Әлфия апа янәшәсенә куйды. Кайтып җитүгә, Әлфия апабыз шул шешәләрне тигез итеп барыбызга бүлеп бирмәсенме?! Шунда аның юмартлыгына исебез китеп: «Без булсак, бүлеп

тормас идек», – диеп көлештек. Бер шешә бирмәсә дә, үпкәләми идек. Ул бит, югыйсә, аңа аталып бирелгән күчтәнәч.

Әлфия апа белән эшләп йөргән еллар күңелле, рәхәт вакыйгаларга бай булды. Бервакыт Актанышка барып 22 бәлеш ашап кайттык, көн саен – ике бәлеш! Күп кеше очын-очка ялгый алмаган заманнарда телне йотарлык тәмле бәлешләр генә аша әле син бөтен бригадаң белән! Бу нәрсәне аңлата соң?.. Әлбәттә инде, Актаныш ягы үз газиз баласын, моңлы сандугачкаен шулай нык яратканын аңлата!

Күп җирләрдә йөрдек, концертлар планын үтәп кенә калмыйча, хәтта арттырып үти торган идек. Кайда барсак та, кибеткә йөгерәбез, кем нәрсә ала. Берсендә баянчы Равил Закиров бер тартма тимер кыстыру җайланмасы (плоскогубцы) алды. Аны ничек күтәргәндер, ул авыр тартманы күтәреп ничекләр кайтып җиткәндер?.. Болар барысы да рәхәт тормыштан түгел, вакытына карап, без дә алыпсатарларга әвереләдек, ничек булса да тормышны алып барыр өчен тырыштык.

Әлфия Авзалованың иҗатына килгәндә, ул һәрбер җырның үз образын тудыра белә иде, аның һәрбер җыры – бер тамаша, спектакль! Бүгенге җырчылар арасында да аңа охшатып җырларга теләүчеләр күп, әмма Әлфия апага талант күктән дә иңгән, тормыш тәҗрибәсе белән дә алган, ул җырның сулышын тоя. Укып, үз өстендә эшләп, яши-яши җырны җаны белән тоемлаучы җырчылар да байтак кына, әмма Әлфия апа кебеген табу мөмкин түгел, андыйлар йөз генә түгел, мең елга бер генә туа! Хәзерге тамашачылар белән элеккеге тамашачыларны да чагыштырып булмый. Бер сүзне кабатлап торган эчтәлексез җырларны да тамашачы бүген алкышларга күмә. Бу бер көнлек җырларны халыкның ятратуы күңелгә шом сала. Җыр өлкәсендә Әлфия апабыз, чыннан да, халык күңелен яулаган бөек җырчы! Күңелгә Әлфия апаның моңнары, Илһам абыйның җырлары тансык. Алар икесе дә – кабатланмас талант ияләре! Ә без – шул бөек җырчыларны тыңлап үскән бәхетле буын. Әле бүгенгедәй исемдә: минем кечкенә вакыт, Әлфия апа безнең авылга концерт куярга килде. Өстендә шундый матур, кыска итәкле, караңгы кызыл төстәге күлмәк, ике кулына чәчәктәй итеп киендергән ике кызын җитәкләгән. Әлфия апа дигәч, гел күз алдыма ул шушы халәттә килеп баса. Әйе, ялгыз канат ике кыз бала үстергән, моңнарында бөтен татар халкын тәрбияләгән бу олуг затка баш имичә нәрсә эшлисең?.. Бу юлны, ул узган юлларны үтәр өчен тимер аяклы, ат йөрәкле, галәмнең үзе кебек киң күңелле булу кирәк! Әлфия апа татар хатын-кызларының өлгесе, сабырлык күрке, моң дәрьясы! Урының оҗмахта булсын, бик тә сагынабыз сине, Әлфия апа! Синең якты истәлегең безнең күңелләрдән мәңге китмәс! Син үзеңнең матур җырларыңда, үлмәс моңнарыңда яшәрсең!